

# КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ

**№4**

Гыйнвар, 2014 нче ел

Теләче муниципаль районы   Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе

Бу санда

* Хуш , 2013 ел !

*Кышкы бизәкләр.

*Узып баручы вакыйгаларга күзәтү.

*Тамчы- тамчы яңалык.

*Ленинград блокадасы өзелүгә-70 ел.

*Ял сәгатьләрендә

## *Хуш , 2013 ел !*

Яңа ел алдыннан узып баручы елга нәтиҗәләр ясау гадәте бар. 2013 ел Татарстанлылар өчен нинди булды?Нинди уңышларга ирештек,ниләр шаккаттырды,нәрсәгә шатландык?..XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы,әлбәттә инде,узып баручы елның төп вакыйгасы булды.2013 елгы Универсиаданы халыкара дәрәҗәдә тарихта иң яхшысы дип таныдылар.Уеннарны ачу тантанасы 4 сәгать дәвам итте,гомумән алганда, аны бөтен дөнья буенча 1 миллиардтан артык кеше карады.Спорт ярышлары шулай ук үзенең колачы белән таң калдырды:162 илдән килгән 11759 спортчы арасында спортның 27 төре буенча 351 комплект медаль уйнатылды.Медальләр һәм рекордларның күбесе-Россия җыелма командасы исәбендә.

## Моны белү кызык

- **2014 нче ел Дәрдмәнд елы дип игълан ителде**
- **Казан-төрки дөньяның мәдәни башкаласы**
- **Тиздән Сөембикә образын Казан сәхнәсендә күрергә мөмкин булачак.**



## *Олимпиада - Сочида*




Олимпия уеннарына Россия жыелма командасы составында Татарстан данын 8 спортчы яклаячак. Шуларның 4се -“Ак Барс” хоккей командасы уенчылары Александр Свитов, Алексей Терещенко, Евгений Медведев, Илья Никулин, тагын 4-се - чаңгы спорты вәкилләре Нияз Нәбиев, Иван Панин, Наталья Жукова һәм Анастасия Доценко. 7-16 март көннәрендә узачак Паралимпия уеннары да безнең спортчылардан башка узмаячак. Бу ярышларда республикадан ике чаңгычы – Марта Зәйнуллина һәм Рушан Миңнегулов катнашачак.



## *2014 нче ел-мәдәният елы*

**Май аенда якташыбыз-узган ел «Голос» проектында җиңгән Динә Гарипова– Швециянең Мальмё шәһәрендә үткәрелгән “Евровидение” халыкара бәйгесендә катнашып,янә вакыйгалар үзәгендә булды.Яшел Үзәндә — Динә Гарипованың туган шәһәрендә аның чыгышын үзәк мәйданда урнаштырылган зур плазмалы экраннан трансляцияләделәр.Динә 5 урынны яулады.Динәгә зур уңышлар юлдаш булсын!**

* * * **22 гыйнварда Казанда “Татарстан гүзәле-2014” конкурсы үтте.Анда башкалабыздан 22 яшьлек Динара Акбашева җиңеп чыкты.Ул Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында укый, дизайнер-проектлаучы һөнәрен башкара.**

* * * **Районыбызның бер төркем җырчылары “ Татарстан –Яңа гасыр” телеканалында зур популярлык белән баручы “Җырлыйк әле” тапшыруында катнашып кайттылар.**

## ***Без күңелле яшибез***



*Матур чыршы бәйрәмнәреннән соң,озын каникул көннәре башланып китте.Без вакытыбызны бушка уздырмадык,рәхәтләнеп уйнадык,тауда чанада шудык,саф һава суладык,*



*түгәрәкләргә йөрергә дә вакыт таптык.*



## ***Мәктәп тормышыннан тамчы-тамчы яңалык***

**Эшлекле киңәшмәләр,очрашулар...**



^^^ **"Яңа федераль дәүләт стандартларына күчкәндә укыту-тәрбия процессының сыйфатын күтәрү"**темасы астында мәктәптә педагогик киңәшмә булып узды.



^^^ Мәктәбебезнең математика һәм информатика укытучысы Галимҗанова Г.Ә. **"Математика патшасы"** дип исемләнгән иртә үткәрде. Ул бөек рус математигы , механигы, дөньядагы беренче математик хатын-кыз ,профессор Софья Васильевна Ковалевскаяга багышланды.

^^^ 16.01.2014 көнне мәктәбебездә **"Яхшы уку өчен балага ничек ярдәм итәргә"** дигән темага әти-әниләр җыелышы булып үтте.



## *Ленинград блокадасы өзелүгә-70 ел.*


*Ленинград блокадасы өзелүгә 70 ел булу уңаеннан мәктәбебездә күп кенә чаралар,сыйныф сәгатьләре булып үтте.*



(5 нче сыйныфта "Онытырга хакыбыз юк" темасына тәрбия сәгате)



(6 нчы сыйныф укучылары блокада корбаннарын бер минутлык тынлык белән искә алды.)



(7 нче сыйныфта "Тормыш юлы" темасына сыйныф сәгате)

## Тарихыбызны барлаганда ...



**31 нче гыйнвар көнне тарих фәннәре кандидаты ,Татарстан фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институтының татар халкы тарихын өйрәнүче галим-язучы Рәшит Галләм килде. Аның төп максаты-авылдашыбыз, фәлсәфә фәннәре докторы , профессор Яхъя Абдуллинның күпьеллык хезмәтен дәвам итеп, Олы Кибәхуҗа авылы тарихын язу. Р.Галләм укучыларга авыл тарихы турында материалларның Татарстан милли архивында, Мәскәү шәһәренең сирәк документлар архивында, Уфадагы һәм С.- Петербургтагы архивларда саклангалыгын, тарихны шул материалларга нигезләнеп язарга җыенуы турында сөйләде, 7 буын бабаларын белергә кирәк икәнлеге турында киңәшләр бирде. Укучыларда авылыбыз тарихы белән кызыксыну тагын да артты һәм алар язучы абыйларына ярдәм йөзеннән, авылның өлкән кешеләре белән очрашып, материаллар тупларга ышандырдылар.**

&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&&

# Күңелебездә иман булсын!



**Котлыйбыз!**

**Хөрмәтле укытучыларыбыз Ильмира Мансуровна һәм Наилә Дәүләтжановна!**

Сезне чын күңелебездән гомер бәйрәмегез- **туган көннәрегез** белән тәбрик итәбез.Сезгә эшегездә һәм тормышыгызда зур уңышлар, кайгы-хәсрәтсез көннәр , чиксез шатлыклар,күңел тынычлыгы телибез.

Шулай ук гыйнвар аенда үзләренең туган көннәрен билгеләп үтүче дусларыбызга да иң изге теләкләребезне житкерәбез. Бәхетле булыгыз!



# Ял сәгатьләрендә



**Кыш көне нәрсә артык?**

## Ребусны чишегез




**Газетаны гамәлгә куючы:**
Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе

**Адрес:**
422080,ТР, Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авылы,Кече урам, 10 нчы йорт

**e-mail:** mkibiakozi40@mail.ru

**Редактор:**
Закирова Гөлназ Миннехан кызы

**Редколлегия әгъзалары:**
VII сыйныф укучылары